ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш, Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш., Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 72 от «19» 02 2021 г.

Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитеты каршындагы
Яшьләр белән эшләү буенча иҗтимагый
координация Советы турындагы
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында Террорга каршы комиссиясенең 2017 елның 24 октябрендәге ПР-313 номерлы Карарын үтәү йөзеннән һәм Мамадыш муниципаль районы территориясендә Дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру, яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегенә, аларның дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлегенә кагылышлы мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр эшләү, Мамадыш муниципаль районында яшьләр проблемаларын хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләү максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 нче елның 8 февралендәге 136 нчы карары белән расланган Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Яшьләр белән эшләү буенча иҗтимагый координация Советы турындагы Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 22 пунктындагы 15 абзацын төшереп калдырырга;
- Нигезләмәнең 5.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Яшьләр Координация советы утырышы беркетмәсе, аның компетенциясе нигезендә кабул ителгән, рәис һәм секретарь тарафыннан Яшьләр Координация советы утырышы уздырылган көнне рәсмиләштерелә һәм имзалана».
- Нигезләмәнең 5.11 пунктын түбәндәге редакциядә санарга: «районда Яшьләр Координация Советының яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча карарлары Яшьләр Координация советы утырышын үткәрү көнендә муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына җибәрелә».

2.Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми mamadysh.tatarstan.ru сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый порталында урнаштырырга.

0000010773

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р.Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче — И.М.Дәрҗеманов